**НӘТИҖӘ 2**

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Лебяжье авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру нәтиҗәләре турында**

Үткәрү датасы: 27.02.2026
Үткәрү вакыты: 14.00
Үткәрү урыны: Лебяжье авыл җирлеге башкарма комитеты бинасы

**Гавами тыңлаулар предметы:** Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Лебяжье авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проектын карау.

**Гавами тыңлаулар үткәрү өчен нигез:** Лебяжье авыл җирлеге Башлыгының «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Лебяжье авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында»29.01.2026 ел, № 1 карары

**Гавами тыңлауларның инициаторы:** Лебяжье авыл җирлеге башлыгы.

Гавами тыңлаулар уздыру турындагы мәгълүмат 29.01.2026 елдан башлап Алексеевск муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча урнаштырылды:http://alekseevskiy.tatarstan.ru/, шулай ук мәгълүмат стендында урнаштырылган:

- Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Лебяжье авыл җирлеге Башкарма комитетының административ бинасы: Лебяжье авылы, Центральная ур., 27А йорт;
- Лебяжье авылы мәдәният йорты, Лебяжье авылы, Центральная ур., 29А йорт.

Гавами тыңлауларда катнашучылар саны 23кеше тәшкил итте.

Әлеге бәяләмә 27.02.2026 ел, № 2 гавами тыңлаулар беркетмәсе нигезендә әзерләнде

Гавами тыңлаулар вакытында Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Лебяжье авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр Лебяжье авыл җирлеге администрациясенә кермәде.

Гавами тыңлаулар үткәрү чорында 27.02.2026 елда Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Лебяжье авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проекты уңай бәя алды.

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Лебяжье авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәсе һәм тәкъдимнәре:

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Лебяжье авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проектын әзерләү буенча Комиссия, проект буенча бирелгән материалларны,

гавами тыңлаулар беркетмәсен карап чыгып, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Лебяжье авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү процедурасы үтәлгән һәм Россия Федерациясе законнары таләпләренә һәм Лебяжье авыл җирлегенең муниципаль хокукый актларына туры килә дип саный, шуңа бәйле рәвештә уздырылган гавами тыңлауларны узган дип таный.

2. Комиссия Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Лебяжье авыл җирлеге башкарма комитетына гавами тыңлаулар үткәрү буенча материалларны Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы комиссиясенә тапшырырга тәкъдим итә.

Әлеге бәяләмәне Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Лебяжье авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru).

**Рәис:** **Д.Ә.Гыйләҗов**

**Секретарь** **Н.Г.Каныгина**